**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

КАРАР

2019 елның 30 нче октябре № 1

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегендә Шахмай авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Шахмай авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге башлыгы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында Хамит Хәйруллин урамы буенча 17-40, Сөембикә урамы буенча 1-22 нче йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 13 ноябрь көнне сәгать 10.00 га Шахмай авылында Хамит Хәйруллин урамы, 26 йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында Үзәк урам буенча 59-115 һәм 52-94, Чишмә урамы буенча 1-17 йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 13 ноябрь көнне сәгать 14.00 га Шахмай авылында Үзәк урам, 75 йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында Яшьләр урамы буенча 1-9; Яңа урам буенча 1-4 йорттан; Хамит Хәйруллин урамы буенча 1-16 нче йортларында яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының

өченче этабын 2019 елның 14 ноябрендә сәгать 10.00 сәгатькә Яшьләр урамы1 нче йорт янында билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында Үзәк урам 38 нче йорт Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын Шахмай урта гомуми белем бирү мәктәбендә 2019 елның 14 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Халык җыенын үткәрү өчен Шахмай авылы халкы исемлеген бүлеп сайлау тәртибе территориаль бүленеш буенча башкарылырга тиеш.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, 75тән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Шахмай авылында түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?: - юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү););- юлларны кардан чистарту; - җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); - чишмәгә ЗСО сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

“РИЗА” "КАРШЫ"

8. Әлеге карарны «Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы И.Г.Гаризов